# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Арча муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп корырга:

1) "Венета авыл җирлеге"н һәм "Иске Чүриле авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Иске Чүриле авылы булган "Иске Чүриле авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән;

2) "Кушлавыч авыл җирлеге"н һәм "Утар Аты авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Утар Аты авылы булган "Утар Аты авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән;

3) "Күпербаш авыл җирлеге"н һәм "Иске Кырлай авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Түбән Мәтәскә авылы булган "Иске Кырлай авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән;

4) "Яңа Кырлай авыл җирлеге"н һәм "Өчиле авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Яңа Кырлай авылы булган "Яңа Кырлай авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән;

5) "Носы авыл җирлеге"н һәм "Шушмабаш авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Шушмабаш авылы булган "Шушмабаш авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән;

6) "Иске Ашыт авыл җирлеге"н һәм "Ташкичү авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Ашытбаш авылы булган "Ташкичү авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән;

7) "Казанбаш авыл җирлеге"н, "Урта Пошалым авыл җирлеге"н һәм "Үрнәк авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Үрнәк поселогы булган "Үрнәк авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән;

8) "Яңа Кенәр авыл җирлеге"н, "Сөрде авыл җирлеге"н һәм "Шурабаш авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Яңа Кенәр авылы булган "Яңа Кенәр авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән;

9) "Сеҗе авыл җирлеге"н, "Сикертән авыл җирлеге"н һәм "Курса-Почмак авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Курса-Почмак авылы булган "Сеҗе авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән.

**2 статья**

1. Яңа төзелгән "Яңа Кенәр авыл җирлеге", "Яңа Кырлай авыл җирлеге", "Сеҗе авыл җирлеге", "Иске Кырлай авыл җирлеге", "Иске Чүриле авыл җирлеге", "Ташкичү авыл җирлеге", "Үрнәк авыл җирлеге", "Утар Аты авыл җирлеге", "Шушмабаш авыл җирлеге" (алга таба – яңа төзелгән муниципаль берәмлекләр) муниципаль берәмлекләренең беренче чакырылыш вәкиллекле органнары депутатларының һәм беренче башлыкларының вәкаләтләре чорын биш ел дип билгеләргә.

2. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең беренче чакырылыш вәкиллекле органнарындагы депутатлар санын ун кеше тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларга әзерләнү һәм аларны үткәрү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумнарда кабул ителүче яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарда башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлап куела.

Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан артыграгы аны хуплап тавыш бирсә, бу муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы дип санала.

Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлек башлыгын сайлап куйганчы, бу муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары утырышын вәкиллекле органның яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара;

2) һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

"Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш); 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"**3 статья.** "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 4 – 32 нче кушымталар) нигезендә билгеләргә, аларга авыл җирлеге статусы бирергә һәм административ үзәкләрен билгеләргә:

Апаз авыл җирлеге: Апаз (административ үзәк), Пөшәңгәр, Хәсәншәех, Каратай, Кызыл Игенче, Миржәм авыллары;

Кәче авыл җирлеге: Кәче (административ үзәк), Кишмәт, Чулпан, Абҗабар, Якты Көн авыллары;

Наласа авыл җирлеге: Наласа (административ үзәк), Урта Бирәзә авыллары;

Яңа Кенәр авыл җирлеге: Яңа Кенәр (административ үзәк), Байкал, Кызылъяр, Түбән Оры, Сөрде, Шура, Шурабаш, Югары Оры, Кече Әтнә, Яңа Сәрдә, Яңа Ашыт авыллары;

Яңа Кишет авыл җирлеге: Яңа Кишет (административ үзәк), Иске Кишет, Кышкар, Симетбаш авыллары;

Яңа Кырлай авыл җирлеге: Яңа Кырлай (административ үзәк), Күкчә Бирәзә, Яңа Иябаш, Өчиле, Чиканас, Югары Бирәзә, Иске Йорт, Пионер авыллары;

Сеҗе авыл җирлеге: Курса-Почмак (административ үзәк), Гөберчәк, Мөрәле, Яңа Ключище, Яңа Чүриле, Сеҗе, Сикертән, Югары Масра, Казаклар, Иске Масра, Иске Муй, Ташкич, Чәмә-Елга авыллары, Курса тимер юл разъезды поселогы, Пүчинкә-Поник поселогы;

Урта Аты авыл җирлеге: Түбән Аты (административ үзәк), Урта Аты, Урта Сәрдә, Әрнәш, Колачы авыллары;

Урта Курса авыл җирлеге: Урта Курса (административ үзәк), Югары Курса, Сарай-Чокырча, Алан, Корайван, Түбән Курса авыллары, Сарай-Чокырча тимер юл разъезды;

Иске Кырлай авыл җирлеге: Түбән Мәтәскә (административ үзәк), Югары Әзәк, Иске Кырлай, Югары Мәтәскә, Казиле, Мөндеш, Иске Иябаш, Өтнә авыллары;

Иске Чүриле авыл җирлеге: Иске Чүриле авылы (административ үзәк), Ашабаш, Венета, Штерә, Ермоловка, Красная Горка, Платоновка, Татар Кадрәге авыллары, Чүриле тимер юл разъезды поселогы, Михайловка поселогы;

Ташкичү авыл җирлеге: Ашытбаш авылы (административ үзәк), Мәмсә, Иске Ашыт, Ташкичү, Хәтнә, Акчишмә, Кысна, Наратлык, Печмәнтау, Иске Кенәр авыллары;

Үрнәк авыл җирлеге: Үрнәк поселогы (административ үзәк), Бимәр, Югары Пошалым, Казанбаш, Күлтәс, Урта Пошалым, Иске Төрнәле, Алга-Көек, Апайкина-Гарь, Казанка, Көтек, Кече Төрнәле, Түбән Пошалым, Тылаңгыр авыллары, Гарталовка, Дүртөйле поселоклары;

Утар Аты авыл җирлеге: Утар Аты (административ үзәк), Югары Аты, Субаш Аты, Орнашбаш, Кушлавыч, Иске Җөлби авыллары;


Шушмабаш авыл җирлеге: Шушмабаш авылы (административ үзәк), Носы, Сәрдәбаш, Шекә, Илдус, Ишнарат, Үгез-Елга авыллары;

Яңасала авыл җирлеге: Яңасала (административ үзәк), Каенсар авылы.";

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре
# **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 13(12)-8(13) | - Марий Эл Республикасы |
| 8(13)-24 (50) | - Балтач муниципаль районы |
| 24(50)-58(49) | - Саба муниципаль районы |
| 58(49)-66(48) | - Теләче муниципаль районы |
| 66(48)-64(46) | - Питрәч муниципаль районы |
| 64(46)-53(47) | - Биектау муниципаль районы |
| 53(47)-13(12) | - Әтнә муниципаль районы |

"Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлекләр |
|---|---|
| 1 | Арча шәһәре |
| 2 | Апаз авыл җирлеге |
| 3 | Кәче авыл җирлеге |
| 4 | Наласа авыл җирлеге |
| 5 | Яңа Кенәр авыл җирлеге |
| 6 | Яңа Кишет авыл җирлеге |
| 7 | Яңа Кырлай авыл җирлеге |
| 8 | Сеҗе авыл җирлеге |
| 9 | Урта Аты авыл җирлеге |
| 10 | Урта Курса авыл җирлеге |
| 11 | Иске Кырлай авыл җирлеге |
| 12 | Иске Чүриле авыл җирлеге |
| 13 | Ташкичү авыл җирлеге |
| 14 | Үрнәк авыл җирлеге |
| 15 | Утар Аты авыл җирлеге |
| 16 | Шушмабаш авыл җирлеге |
| 17 | Яңасала авыл җирлеге |

";

3) 3 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге Кәче, Наласа, Урта Курса, Иске Кырлай, Яңасала авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацта "Күпербаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Иске Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә, "Күпербаш һәм Наласа" сүзләрен "Наласа һәм Иске Кырлай" сүзләренә һәм "Күпербаш һәм Урта Курса" сүзләрен "Урта Курса һәм Иске Кырлай" сүзләренә алмаштырырга;

4) 4 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Носы," сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта "Носы" сүзен "Шушмабаш" сүзенә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Апаз авыл җирлеге чиге Шушмабаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Апаз, Ташкичү һәм Шушмабаш авыл җирлекләре тоташкан җирдә Хәтнә авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан

алып 770 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасы буйлап бара, аннары 1,3 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, Апаз – Шушмабаш автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,0 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап профильле автомобиль юлына кадәр бара, аннары 250 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, шуннан соң 1,0 км көнчыгыш юнәлештә Шушма елгасы буенча уза, аннары 320 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка борыла һәм 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча Апаз – Ишнарат автомобиль юлы белән кисешкәнче уза, аннары 800 м төньяк-көнбатыш юнәлештә әлеге автомобиль юлының көньяк-көнбатыш ягы буйлап бара, бу автомобиль юлын кисеп чыга, шуннан соң шул ук юнәлештә 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча, Носы – Миржәм автомобиль юлын кисеп үтеп, 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

г) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 5 нче һәм 6 нчы кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга;

6) 7 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Венета," сүзен төшереп калдырырга;

б) сигезенче абзацта "Венета, Кәче" сүзләрен "Кәче, Иске Чүриле" сүзләренә алмаштырырга;

в) тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кәче авыл җирлеге чиге Иске Чүриле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 62 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә көньяк-көнбатышка таба "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 5, 4, 12, 13 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап әлеге урманчылыктагы 13 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, "Казан – Малмыж" – Венета автомобиль юлын кисеп үтеп, 220 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча бара, шуннан соң "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба бара, аннары "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 17, 14 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап шул ук юнәлештә 2,7 км уза, урман полосасын һәм Казан – Малмыж автомобиль юлын кисеп үтеп, 3,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 590 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, шуннан соң 300 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба борыла һәм 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкәнче бара, 500 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап бара, инешне кисеп үтә, төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, инешне кисеп үтеп, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча бара, 200 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казансу елгасы белән кисешкәнче бара, шуннан соң шушы елга

агымы буенча 8,0 км аска таба Кәче, Иске Чүриле авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кишмәт авылыннан 880 м көньяк-көнбатышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

7) 8 нче һәм 9 нчы кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга;

8) 10 нчы кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Наласа авыл җирлеге "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Кәче, Яңа Кырлай, Урта Аты, Иске Кырлай һәм Утар Аты авыл җирлекләре белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацта "Өчиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Яңа Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә алмаштырырга, "Утар Аты һәм Өчиле" сүзләрен "Яңа Кырлай һәм Утар Аты" сүзләренә, "Күпербаш, Наласа һәм Өчиле" сүзләрен "Наласа, Яңа Кырлай һәм Иске Кырлай" сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта "Күпербаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Иске Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә алмаштырырга, "Күпербаш һәм Наласа" сүзләрен "Наласа һәм Иске Кырлай" сүзләренә алмаштырырга;

9) 11 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

**Арча муниципаль районының "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яңа Кенәр авыл җирлеге Ташкичү, Шушмабаш авыл җирлекләре, Әтнә муниципаль районы һәм Марий Эл Республикасы белән чиктәш.

**Арча муниципаль районының "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Яңа Кенәр авыл җирлеге чиге Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдә Яңа Кенәр авыл җирлеге, Әтнә муниципаль районы һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Кызылъяр авылыннан 6,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 13 нче (12 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буенча Яңа Кенәр, Шушмабаш авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Ашыт авылыннан 2,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Кенәр авыл җирлеге чиге Шушмабаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатыш юнәлештә "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 40, 39 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, Шушмабаш – Яңа Ашыт профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,0 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шушма елгасына кадәр бара, шуннан соң шушы елга агымы буенча аска таба елгага кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр 1,4 км уза, аннары 1,8 км шушы елга агымы буенча өскә таба Яңа Кенәр, Ташкичү һәм Шушмабаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Шекә авылыннан 1,6 км көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Кенәр авыл җирлеге чиге Ташкичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 75 м көнбатышка таба, 87 м көньякка таба, 280 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 440 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 270 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,1 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 800 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 1,1 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча аска таба икенче кибеп баручы инеш белән кушылган җиргә кадәр 4,2 км бара, аннары шушы инеш агымы буенча өскә таба 850 м бара, шуннан соң 110 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, Яңа Кенәр – Иске Кенәр автомобиль юлын кисеп үтеп, урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, Яңа Кенәр – Түбән Оры автомобиль юлын һәм күлне кисеп үтеп, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, "Арча – Марий Эл Республикасы чиге" – Сөрде автомобиль юлын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 2,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 530 м төньяк-көнбатышка таба, Печмәнтау елгасын кисеп үтеп, 280 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле ике автомобиль юлын кисеп үтеп, урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 1,2 км уза, шуннан соң гомуми юнәлештә урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 880 м көньяк-көнбатышка таба, 470 м профильле автомобиль юлы буйлап, 2,5 км урман полосасының көнчыгыш ягы буйлап Яңа

Кенәр, Ташкичү авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Печмәнтау авылыннан 1,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Кенәр авыл җирлеге чиге Әтнә муниципаль районы белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чиге буйлап 13 нче (12 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Кенәр авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдә Яңа Кенәр авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Кече Әтнә авылыннан 3,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 1 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

11) 12 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кырлай, Ташкичү, Утар Аты авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) бишенче һәм алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яңа Кишет авыл җирлеге чиге Ташкичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кишет, Ташкичү авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кышкар авылыннан 2,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба Кышкар – Иске Ашыт автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә бу автомобиль юлы буйлап 680 м үтә, шуннан соң көньяк-көнчыгышка борыла һәм бу автомобиль юлы белән 280 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км бара, аннары шул ук юнәлештә, сынык сызык ясап, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Арча – Марий Эл Республикасы чиге һәм "Арча – Марий Эл Республикасы чиге" – Ашытбаш автомобиль юлларын кисеп үтеп, 2,6 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Яңа Кишет, Яңа Кырлай һәм Ташкичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Симетбаш авылыннан 1,9 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Кишет авыл җирлеге чиге Яңа Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 480 м көньяк-көнбатышка таба, 280 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кышкар – Субаш Аты автомобиль юлы белән кисешкәнче уза, аннары шул ук юнәлештә, "Арча – Марий Эл Республикасы чиге" – Яңа Кишет автомобиль юлын кисеп үтеп, Кышкар – Субаш Аты автомобиль юлы буйлап 960 м уза, 210 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 105 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм бу урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң гомуми юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба әлеге урманчылыктагы 105, 107, 109 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 5,3 км бара, аннары "Арча

урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 109, 108 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 5,1 км уза, аннары бу урманчылыктагы 110 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатыш юнәлештә 1,5 км Яңа Кишет, Яңа Кырлай һәм Утар Аты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Кишет авылыннан 4,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

г) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

12) 13 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
13 нче кушымта

**Арча муниципаль районының**
**"Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яңа Кырлай авыл җирлеге Наласа, Яңа Кишет, Иске Кырлай, Ташкичү, Үрнәк һәм Утар Аты авыл җирлекләре белән чиктәш.

**Арча муниципаль районының**
**"Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чиге**

Яңа Кырлай авыл җирлеге чиге Ташкичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кишет, Яңа Кырлай һәм Ташкичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Симетбаш авылыннан 1,9 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 63 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары 2,0 км шушы урманчылыктагы 63, 60 нчы урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, шуннан соң көнчыгыш юнәлештә 2,7 км "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы

60, 61, 62 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 57 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, шуннан соң әлеге урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 390 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары көньякка борыла һәм 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап үтә, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 230 м, көнчыгыш чиге буйлап 620 м Яңа Кырлай, Ташкичү һәм Үрнәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Пионер авылыннан 2,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Кырлай авыл җирлеге чиге Үрнәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м көньяк-көнбатышка таба, 240 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 170 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 340 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Пошалым елгасының чишмә башына кадәр уза, аннары Пошалым елгасы агымы буенча аска таба 1,1 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, 260 м урман полосасы буйлап, 490 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап автомобиль юлына кадәр уза, аннары 2,1 км көньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлы буйлап Яңа Кырлай, Иске Кырлай һәм Үрнәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Пионер авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Кырлай авыл җирлеге чиге Иске Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба аның Өтнә елгасына койган җиргә кадәр 800 м уза, шушы елга агымы буенча өскә таба 450 м бара, аннары 1,5 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кече Өтнә елгасына кадәр уза, шушы елга агымы буенча өскә таба 350 м бара, аннары 210 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасы буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң шушы урманчылыктагы 104, 103 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары 400 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ия елгасына кадәр бара, Ия елгасы агымы буенча өскә таба 500 м бара, аннары, Яңа Ийбаш – Югары Әзәк автомобиль юлын һәм урман полосасын кисеп үтеп, 1,0 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара. Шуннан соң чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,3 км Арча – Марий Эл Республикасы чиге автомобиль юлы буйлап бара, аннары 5,6 км әлеге автомобиль юлы буендагы урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шул ук юнәлештә 3,36 км Арча – Марий Эл Республикасы чиге автомобиль юлы буйлап, 240 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш ягыннан бара, шуннан соң 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба, 320 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 880 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 1,2 км аска таба Наласа, Яңа Кырлай һәм Иске Кырлай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кукчә Бирәзә авылыннан 1,9 км көнчыгышта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Кырлай авыл җирлеге чиге Наласа авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Наласа, Яңа Кырлай һәм Утар Аты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Йорт авылыннан 1,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш юнәлештә 570 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Наласа – Яңа Кишет профильле автомобиль юлын ике мәртәбә кисеп үтеп, урман полосасына кадәр уза, 260 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 170 м урман полосасы буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 3,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, Наласа – Күкчә Бирәзә профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 410 м урман полосасының төньяк чиге буйлап бара, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырга кадәр, аннары гомуми юнәлештә чокыр буйлап 690 м көнчыгышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, профильле автомобиль юлын һәм инешне кисеп үтеп, 290 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 740 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягыннан, 670 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 49 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Кырлай авыл җирлеге чиге Утар Аты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кишет, Яңа Кырлай һәм Утар Аты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Кишет авылыннан 4,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 110, 112 нче урман кварталларының көнбатыш чикләре буйлап, аннары 114 нче урман кварталының төньяк, көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 970 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,7 км көньяк-көнчыгышка таба 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Кырлай авыл җирлеге чиге Яңа Кишет авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 480 м көньяк-көнбатышка таба, 280 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кышкар – Субаш Аты автомобиль юлы белән кисешкәнче уза, аннары шул ук юнәлештә, "Арча – Марий Эл Республикасы чиге" – Яңа Кишет автомобиль юлын кисеп үтеп, Кышкар – Субаш Аты автомобиль юлы буйлап 960 м уза, 210 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 105 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм бу урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң гомуми юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба әлеге урманчылыктагы 105, 107, 109 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 5,3 км бара, аннары "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 109, 108 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, автомобиль юлы белән кисешкәнче 5,1 км уза, аннары бу урманчылыктагы 110 нчы урман кварталының төньяк-

көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатыш юнәлештә 1,5 км 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

13) 14 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

14) 15 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
15 нче кушымта

**Арча муниципаль районының**
**"Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Сеҗе авыл җирлеге Урта Курса, Иске Кырлай, Үрнәк авыл җирлекләре, Балтач һәм Саба муниципаль районнары белән чиктәш.

**Арча муниципаль районының**
**"Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чиге**

Сеҗе авыл җирлеге чиге Балтач муниципаль районы белән чиктәш җирдә Сеҗе, Үрнәк авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бимәр авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чиге буйлап Сеҗе авыл җирлеге, Балтач һәм Саба муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Пүчинкә-Поник авылыннан 1,8 км төньякта урнашкан 24 нче (50 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Сеҗе авыл җирлеге чиге Саба муниципаль районы белән чиктәш җирдә 24 нче (50 нче) тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чиге буйлап Сеҗе, Урта Курса авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы чикләре тоташкан урында Курса-Почмак авылыннан 1,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Сеҗе авыл җирлеге чиге Урта Курса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 46 нчы тоташу ноктасыннан алып Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,5 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары урман

полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 260 м төньяк-көнбатыш юнәлештә бара, 850 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сазлыкны әйләнеп үтеп, 590 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягыннан бара, 80 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр, шуннан соң 2,0 км инеш агымы буйлап аска таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м көньяк-көнбатышка таба, 140 м көнбатышка таба, 180 м көньяк-көнбатышка таба, Кисмәс елгасын кисеп үтеп, 600 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 600 м төньякка таба чокыр буенча бара, шуннан соң, Югары Курса – Иске Масра профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 80 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр бара, 3,0 км урман полосасы буйлап Сеҗе, Урта Курса һәм Иске Кырлай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Курса авылыннан 3,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 67 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Сеҗе авыл җирлеге чиге Иске Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сеҗе, Иске Кырлай һәм Үрнәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Казанбаш авылыннан 2,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып 450 м көньяк-көнбатышка таба Казиле – Югары Масра автомобиль юлының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап уза, бу автомобиль юлын кисеп үтә һәм 1,0 км аның төньяк-көнбатыш ягы буйлап бара, бу автомобиль юлын кабат кисеп үтә һәм 67 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Сеҗе авыл җирлеге чиге Үрнәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Сурнар участок урманчылыгындагы 68, 77, 88 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң бу урманчылыктагы 99, 98, 97, 96 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба, аннары бу урманчылыктагы 96, 107, 116, 120 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатыш юнәлештә уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 120 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, 260 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба урман полосасына кадәр бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба, 300 м көньякка таба бара, шуннан соң урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 560 м көньяк-көнбатышка таба автомобиль юллары кисешкән җиргә кадәр бара, 510 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казиле – Югары Масра профильле автомобиль юлының көньяк-көнчыгыш ягыннан 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

15) 16 нчы һәм 17 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга;

16) 18 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Кушлавыч," сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта "Кушлавыч, Урта Аты" сүзләрен "Урта Аты, Утар Аты" сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Урта Аты авыл җирлеге чиге Утар Аты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 960 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 770 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 120 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 700 м уза, аннары, инешне кисеп үтеп, 330 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасы буйлап уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 670 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 750 м көнчыгышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, аннары 650 м төньяк-көнчыгышка таба чокырның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап инешнең чишмә башына кадәр бара, шуннан соң шушы инеш агымы буенча аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр 640 м бара, аннары шушы инеш агымы буенча аска таба 580 м уза, шуннан соң, "Арча – Олы Әтнә" – Әрнәш автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,8 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 490 м урман полосасының көньяк чиге буйлап Наласа, Урта Аты һәм Утар Аты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Аты авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

17) 19 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта "Күпербаш, Курса-Почмак" сүзләрен "Сеҗе, Иске Кырлай" сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта "Курса-Почмак авыл җирлеге белән чиктәш" сүзләрен "Сеҗе авыл җирлеге белән чиктәш" сүзләренә алмаштырырга, "Курса-Почмак, Урта Курса" сүзләрен "Сеҗе, Урта Курса" сүзләренә алмаштырырга һәм "Күпербаш, Курса-Почмак һәм Урта Курса" сүзләрен "Сеҗе, Урта Курса һәм Иске Кырлай" сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацта "Күпербаш һәм Урта Курса" сүзләрен "Урта Курса һәм Иске Кырлай" сүзләренә алмаштырырга;

г) сигезенче абзацта "Күпербаш авыл җирлеге белән чиктәш" сүзләрен Иске Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш" сүзләренә алмаштырырга;

18) 20 нче һәм 21 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга;

19) 22 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
22 нче кушымта

## Арча муниципаль районының "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Кырлай авыл җирлеге "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Наласа, Яңа Кырлай, Сеҗе, Урта Курса һәм Үрнәк авыл җирлекләре белән чиктәш.

## Арча муниципаль районының "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге

Иске Кырлай авыл җирлеге чиге Яңа Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кырлай, Иске Кырлай һәм Үрнәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Пионер авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба ул Өтнә елгасына койган җиргә кадәр 800 м уза, шушы елга агымы буенча өскә таба 450 м бара, аннары 1,5 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кече Өтнә елгасына кадәр уза, шушы елга агымы буенча өскә таба 350 м бара, аннары 210 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасы буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң шушы урманчылыктагы 104, 103 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары 400 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ия елгасына кадәр бара, Ия елгасы агымы буенча өскә таба 500 м бара, аннары, Яңа Иябаш – Югары Әзәк автомобиль юлын һәм урман полосасын кисеп үтеп, 1,0 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара. Шуннан соң чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,3 км Арча – Марий Эл Республикасы чиге автомобиль юлы буйлап бара, аннары 5,6 км әлеге автомобиль юлы буендагы урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шул ук юнәлештә 3,36 км Арча – Марий Эл Республикасы чиге автомобиль юлы буйлап, 240 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш ягыннан бара, шуннан соң 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба, 320 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 880 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 1,2 км аска таба Наласа, Яңа Кырлай һәм Иске Кырлай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Күкчә Бирәзә авылыннан 1,9 км көнчыгышта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Кырлай авыл җирлеге чиге Үрнәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сеҗе, Иске Кырлай һәм Үрнәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында

Казанбаш авылыннан 2,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып 610 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,3 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, Казансу елгасын кисеп үтеп, 970 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр уза, аннары төньяк-көнбатыш юнәлештә 780 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, Казанбаш – Югары Мәтәскә автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км төньяк-көнбатышка таба, 1,2 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, Казан – Малмыж һәм "Казан – Малмыж" – Иске Кырлай автомобиль юлларын кисеп үтеп, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 360 м "Казан – Малмыж" – Иске Кырлай автомобиль юлының төньяк-көнчыгыш ягыннан авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнчыгышка таба бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап үтә, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 910 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 510 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 680 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 330 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 380 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, шуннан соң профильле автомобиль юлы буйлап 4,5 км төньяк-көнбатышка таба 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Кырлай авыл җирлеге чиге Сеҗе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып 450 м көньяк-көнбатышка таба Казиле – Югары Масра автомобиль юлының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап уза, бу автомобиль юлын кисеп үтә һәм 1,0 км аның төньяк-көнбатыш ягы буйлап бара, бу автомобиль юлын кабат кисеп үтә һәм Сеҗе, Урта Курса һәм Иске Кырлай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Курса авылыннан 1,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 67 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Кырлай авыл җирлеге чиге Урта Курса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 67 нче тоташу ноктасыннан алып 2,2 км кибеп баручы инеш агымы буйлап аска таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 70 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,6 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 80 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, Арча – Югары Курса автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 480 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Урта Курса һәм Иске Кырлай авыл җирлекләре тоташкан урында Төбәк-Чокырча авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Кырлай авыл җирлеге чиге "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Наласа һәм Иске Кырлай авыл җирлекләре тоташкан урында Урта Бирәзә авылыннан 750 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгыш юнәлештә 650 м кибеп баручы инеш буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 470 м көньяк-көнчыгышка таба, 650 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м көньякка таба, Арча – Марий Эл Республикасы чиге автомобиль юлын кисеп

үтеп, 300 м көнчыгышка таба бара, аннары әлеге автомобиль юлының көнчыгыш ягыннан 140 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба уза, шуннан соң автомобиль юлының төньяк-көнбатыш ягыннан авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба Казан – Малмыж автомобиль юлы белән юллар киселешенә кадәр бара, аннары "Казан – Малмыж" – Күпербаш автомобиль юлының төньяк-көнбатыш ягыннан 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, 74 м көнчыгышка таба, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 490 м төньяк-көнчыгышка таба, 137 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 163 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 810 м төньяк-көнчыгышка таба, 306 м көнчыгышка таба, 550 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м көньяк-көнбатышка таба зиратка кадәр уза, шуннан соң бу зират чиге буйлап 198 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м көньяк-көнбатышка таба, 290 м төньяк-көнбатышка таба, 9 м көньяк-көнбатышка таба автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлының төньяк-көнчыгыш ягыннан 5 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары шул ук юнәлештә, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, 36 м бара. Шуннан соң чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 120 м көньякка таба, 145 м көньяк-көнчыгышка таба, 163 м көньяк-көнбатышка таба, 25 м көнбатышка таба, 261 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м көнбатышка таба, 376 м көньяк-көнбатышка таба, 5 м көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары торф эшләнмәләре кырыеннан, дамбаны кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көнчыгышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш юнәлештә 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км дамба буйлап 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Кырлай авыл җирлеге чиге Наласа авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 48 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буйлап өскә таба 2,3 км 49 нчы тоташу ноктасына кадәр уза. ";

20) 23 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча муниципаль районы"<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында"<br>Татарстан Республикасы Законына<br>23 нче кушымта

**Арча муниципаль районының "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Арча муниципаль районы"

муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Чүриле авыл җирлеге Кәче, Яңасала авыл җирлекләре, Биектау, Питрәч һәм Теләче муниципаль районнары белән чиктәш.

**Арча муниципаль районының "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Иске Чүриле авыл җирлеге чиге Кәче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кәче, Иске Чүриле һәм Яңасала авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каенсар авылыннан 3,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 62 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба гомуми юнәлештә "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 5, 4, 12, 13 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап әлеге урманчылыктагы 13 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары, "Казан – Малмыж" – Венета автомобиль юлын кисеп үтеп, 220 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба, аннары шул ук юнәлештә "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 17, 14 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,7 км бара, урман полосасын һәм Казан – Малмыж автомобиль юлын кисеп үтеп, 3,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 590 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап, шуннан соң 300 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба борыла һәм 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән җиргә кадәр бара, инешне кисеп үтеп, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап 500 м бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, инешне кисеп үтеп, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казансу елгасы белән кисешкән җиргә кадәр бара, шуннан соң шушы елга агымы буенча 8,0 км аска таба Кәче, Иске Чүриле авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кишмәт авылыннан 880 м көньяк-көнбатышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Чүриле авыл җирлеге чиге Яңасала авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 62 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 8 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инеш башына кадәр уза, 4,1 км әлеге инеш буйлап Норма елгасына кадәр, аннары бу елга агымы буйлап 1,5 км аска таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,5 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә, Яңасала – Красная Горка автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр, 30 м әлеге урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 560 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Чүриле, Яңасала авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Михайловка поселогыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 61 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Чүриле авыл җирлеге чиге Теләче муниципаль районы белән чиктәш җирдә 61 нче тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чиге буйлап Иске Чүриле авыл җирлеге, Питрәч һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Ермоловка авылыннан 3,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 66 нчы (48 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Чүриле авыл җирлеге чиге Питрәч муниципаль районы белән чиктәш җирдә 66 нчы (48 нче) тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чиге буйлап Иске Чүриле авыл җирлеге, Биектау һәм Питрәч муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Штерә авылыннан 2,9 км көньяк-көнбатышта урнашкан 64 нче (46 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Чүриле авыл җирлеге чиге Биектау муниципаль районы белән чиктәш җирдә 64 нче (46 нчы) тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чиге буйлап 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

21) 24 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

22) 25 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ташкичү авыл җирлеге Апаз, Яңа Кенәр, Яңа Кишет, Яңа Кырлай, Үрнәк, Шушмабаш авыл җирлекләре, Әтнә һәм Балтач муниципаль районнары белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ташкичү авыл җирлеге чиге Яңа Кенәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кенәр, Ташкичү һәм Шушмабаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Шекә авылыннан 1,6 км көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 75 м көнбатышка таба, 87 м көньякка таба, 280 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 440 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 270 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,1 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 800 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 1,1 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча аска таба икенче кибеп баручы инеш белән кушылган җиргә кадәр 4,2 км бара, аннары шушы инеш агымы буенча өскә таба 850 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 110 м көньяк-көнбатышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, Яңа Кенәр – Иске Кенәр автомобиль юлын кисеп үтеп, урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, Яңа Кенәр – Түбән Оры автомобиль юлын һәм күлне кисеп үтеп, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, "Арча – Марий Эл Республикасы чиге" – Сөрде автомобиль юлын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 2,3 км урман

полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 530 м төньяк-көнбатышка таба, Печмәнтау елгасын кисеп үтеп, 280 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле ике автомобиль юлын кисеп үтеп, урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 1,2 км уза, шуннан соң гомуми юнәлештә урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 880 м көньяк-көнбатышка таба, 470 м профильле автомобиль юлы буйлап, 2,5 км урман полосасының көнчыгыш ягы буйлап Яңа Кенәр, Ташкичү авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Печмәнтау авылыннан 1,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ташкичү авыл җирлеге чиге Яңа Кишет авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кишет, Ташкичү авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кышкар авылыннан 2,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба Кышкар – Иске Ашыт автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә бу автомобиль юлы буйлап 680 м үтә, шуннан соң көньяк-көнчыгышка борыла һәм бу автомобиль юлы белән 280 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км бара, аннары шул ук юнәлештә, сынык сызык ясап, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Арча – Марий Эл Республикасы чиге һәм "Арча – Марий Эл Республикасы чиге" – Ашытбаш автомобиль юлларын кисеп үтеп, 2,6 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Яңа Кишет, Яңа Кырлай һәм Ташкичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Симетбаш авылыннан 1,9 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

д) җиденче абзацта "Урта Пошалым һәм Ташкичү" сүзләрен "Ташкичү һәм Үрнәк" сүзләренә алмаштырырга;

е) сигезенче абзацта "Урта Пошалым авыл җирлеге белән чиктәш" сүзләрен "Үрнәк авыл җирлеге белән чиктәш" сүзләренә алмаштырырга һәм "Урта Пошалым, Ташкичү" сүзләрен "Ташкичү, Үрнәк" сүзләренә алмаштырырга;

ж) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Ташкичү авыл җирлеге чиге Әтнә муниципаль районы белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чиге буйлап 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

23) 27 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
27 нче кушымта

## Арча муниципаль районының "Үрнәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама "Үрнәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Үрнәк авыл җирлеге Сеҗе, Ташкичү, Иске Кырлай, Яңа Кырлай авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы белән чиктәш.

## Арча муниципаль районының "Үрнәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге

Үрнәк авыл җирлеге чиге Балтач муниципаль районы белән чиктәш җирдә Ташкичү, Үрнәк авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы чикләре тоташкан урында Хәтнә авылыннан 2,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чиге буйлап Сеҗе, Үрнәк авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бимәр авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Үрнәк авыл җирлеге чиге Сеҗе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Сурнар участок урманчылыгындагы 68, 77, 88 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң бу урманчылыктагы 99, 98, 97, 96 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба, аннары бу урманчылыктагы 96, 107, 116, 120 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатыш юнәлештә уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 120 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км көньяк-көнбатышка таба, 260 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба урман полосасына кадәр бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба, 300 м көньякка таба бара, шуннан соң урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 560 м көньяк-көнбатышка таба автомобиль юллары кисешкән җиргә кадәр бара, 510 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казиле – Югары Масра профильле автомобиль юлының көньяк-көнчыгыш ягыннан Сеҗе, Иске Кырлай һәм Үрнәк авыл җирлекләре тоташкан урында Казанбаш авылыннан 2,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Үрнәк авыл җирлеге чиге Иске Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 610 м авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап, 2,3 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, Казансу елгасын кисеп үтеп, 970 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр уза, аннары төньяк-көнбатыш юнәлештә 780 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, Казанбаш – Югары Мәтәскә автомобиль юлын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 950 м, Казан – Малмыж һәм "Казан – Малмыж" – Иске Кырлай автомобиль юлларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, "Казан – Малмыж" – Иске Кырлай автомобиль юлының төньяк-көнчыгыш ягыннан 360 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 910 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 510 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 680 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 330 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 380 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң профильле автомобиль юлы буйлап 4,5 км төньяк-көнбатышка таба Яңа Кырлай, Иске Кырлай һәм Үрнәк авыл җирлекләре тоташкан урында Пионер авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Үрнәк авыл җирлеге чиге Яңа Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кырлай, Ташкичү һәм Үрнәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Пионер авылыннан 2,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м көньяк-көнбатышка таба, 240 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 170 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 340 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Пошалым елгасының чишмә башына кадәр уза, аннары Пошалым елгасы агымы буенча аска таба 1,1 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, 260 м урман полосасы буйлап, 490 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап автомобиль юлына кадәр уза, аннары 2,1 км көньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлы буйлап 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Үрнәк авыл җирлеге чиге Ташкичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып урман полосасының көньяк-көнбатыш ягыннан 170 м көньяк-көнчыгышка таба, 830 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 260 м урман полосасы буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 89, 81, 76 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 3,3 км 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

24) 28 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Утар Аты авыл җирлеге Наласа, Яңа Кишет, Яңа Кырлай, Урта Аты авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацта "Кушлавыч, Утар Аты авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Орнашбаш авылыннан 1,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып" сүзләрен "Урта Аты, Утар Аты авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Әрнәш авылыннан 1,2 км көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып" сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта "Утар Аты һәм Өчиле" сүзләрен "Яңа Кырлай һәм Утар Аты" сүзләренә алмаштырырга;

г) алтынчы абзацта "Өчиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Яңа Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә алмаштырырга һәм "Утар Аты һәм Өчиле" сүзләрен "Яңа Кырлай һәм Утар Аты" сүзләренә алмаштырырга;

д) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Утар Аты авыл җирлеге чиге Урта Аты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 960 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 770 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 120 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 700 м уза, аннары, инешне кисеп үтеп, 330 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасы буйлап уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 670 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 750 м көнчыгышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, аннары 650 м төньяк-көнчыгышка таба чокырның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап инешнең чишмә башына кадәр бара, шуннан соң шушы инеш агымы буенча аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр 640 м бара, аннары шушы инеш агымы буенча аска таба 580 м уза, шуннан соң, "Арча – Олы Әтнә" – Әрнәш автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,8 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 490 м урман полосасының көньяк чиге буйлап 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

е) тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип санарга;

25) 29 нчы һәм 30 нчы кушымталарны үз көчләрен югалткан дип санарга;

26) 31 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Носы," сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта "Носы, Шушмабаш авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Ашыт авылыннан 3,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына" сүзләрен "Апаз, Шушмабаш авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Носы авылыннан 950 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына" сүзләренә алмаштырырга;

з) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип санарга;

г) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шушмабаш авыл җирлеге чиге Апаз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Апаз, Ташкичү һәм Шушмабаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәтнә авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып 770 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба, 800 м урман полосасы буйлап уза, аннары 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, Апаз – Шушмабаш автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,0 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап профильле автомобиль юлына кадәр, аннары 250 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көнчыгыш юнәлештә 1,0 км Шушма елгасы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 320 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка борыла һәм 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Апаз – Ишнарат автомобиль юлы белән кисешкәнче бара, аннары әлеге автомобиль юлының көньяк-көнбатыш ягыннан 800 м төньяк-көнбатыш юнәлештә бара, бу автомобиль юлын кисеп үтә, шуннан соң шул ук юнәлештә 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Носы – Миржәм автомобиль юлын кисеп үтеп, 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

27) 32 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Венета, Кәче" сүзләрен "Кәче, Иске Чүриле" сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта "Венета авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Иске Чүриле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә алмаштырырга, "Венета, Кәче" сүзләрен "Кәче, Иске Чүриле" сүзләренә алмаштырырга һәм "Венета, Яңасала" сүзләрен "Иске Чүриле, Яңасала" сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 53-ТРЗ